# ...МӘРХҮМНЕҢ ДӘФТӘРЕННӘН

Тәңренең бәхетле коллары бар. Алар бер яклы булып яратылалар, җан теләкләре чикле була, хыяллары мадди галәмнең[1] соң пәрдәләрен җыртып, гарше көрсиләрдә[2] эзләнми, алар кечек бер мәгъбүд[3] ясап алалар да[*], шуның чынлыгына камил ышанып, рәхәт-рәхәт гомер итәләр. Нидер эшлиләрме, тарихның гади тармагында сай бер эз калдыраларлармы — алар шуның белән бәхетлеләр, шуның белән алар дөньяда буш, мәгънәсез яшәп үтмәгәнлекләренә ышаналар һәм тыныч вөҗдан белән кабергә баралар.

Болар — дөньяга яшәр өчен, мәсгуд булыр өчен киләләр — һәм булалар.

Ләкин табигать[**] мине бөек бәхеттән мәхрүм яраткан.

---

Анам сөйде — бу миңа бәхет иде, сәгадәт иде. Хәятта башка һичбер мәгънә булмаса, тик шуның өчен, тик анамның сөюен йөрәгемдә хис итәр өчен, тик аның мөлаем, матур күзләре белән минем күзләремә сәгатьләрчә текәлеп утырып, соңра нәзек, йомшак куллары белә мине күкрәгенә алып кыскан минутында йөрәгемдә уянган сәгадәт өчен дөньяда бер түгел, йөз мәртәбә, мең мәртәбә яшәргә мөмкин иде. Ул вакыт белгәнменме-юкмы — ләкин хәзер шулай хис кыйлам, хәзер ул, дөньяда булса, мине сөяр, аның самими[4] сөюе миңа хәятта мәгънә булыр, шул сөю — миңа дөньяны алсу нур эчендә күрсәтер иде.

Соңра Гайшәләр белән бәхетле булдым. Ул миңа — Иләһ[5] иде. Дөнья нур эчендә иде. Вакыт килде, табигать үз хокукына керде. Ул миңа хыянәт итте, шуның белән күктә йолдызлар сүнде, айлы кичәләр кара болыт белән капланды, таң сандугачы да тик риядан, ясалма гыйшыктан сайрыйдыр кебек тоела башлады, язгы гөлләр — матур Гайшәмнең калку күкрәгенә зиннәт булган ул алсу чәчәкләр дә — инде кәгазьдер, шахшы[6] буяучының кулыннан ясалып чыккан чүпрәклердер кебек күренәләр.

---

Яшьлекнең бер дәверендә күп нәрсәгә ышанасың; Алла диләр, гадаләт[7], хакыйкать диләр, һәммә кешеләрнең сәгадәте хакында сөйлиләр, мәгълүм бер шартлар буенча төзеленсә, хәятта бәхет булуын өмит итәләр — яшьлек

---

[1]*Мадди галәмнең*— материаль дөньяның.
[2]*Гарше көрсиләрдә* — күк тәхетләрендә.
[3]*Мәгъбүд* — гыйбадәт кылынган зат.
[*]1914 елгы басмада *кечек бер мәгъбүд ясап алалар да* урынында *хәятта бер Иләһ табалар да.*
[**]1914 елгы басмада *Ходa.*
[4]*Самими* — чын күңелдән.
[5]*Иләһ*— Алла урынына.
[6] *Шахшы* – шакшы, начар.
[7]*Гадаләт* — турылык, гаделлек.

боларга ышана, боларның һәрберен саф җәүһәр дип кабул итә, һәм шуның белән аның хәяты мәгълүм бер дәвердә мәгънәле дә, матур да була.

Бар Тәңренең бәхетле коллары: алар бер яклы булып яратылалар, хәятның ачы тәҗрибәләрен алар татымыйлар, яхуд[8] татысалар да, ул аларның күзен ача алмый, аларның карашларын тирәнәйтеп, яшьлекнең матур хыялларын тарата алмый — алар гомергә шул бәхетле алдану, мәсгудиятле хыял эчендә гомер кичерәләр.

Гөнаһым нидер, нинди җинаятем өчен газап чигәмдер, тәңре мине шул бәхетлеләрдән кылмаган, шулар кебек миңа да мәсгудиятле бер хыял эчендә тыныч вөҗдан белән гомер итү бәхетен бирмәгән.

Мин хәят эзләдем, хәятта мәгънә эзләдем, хәятның барлык рәхәтләрен фида кылдырырлык[9] мәртәбәдә изге була алырлык бер идеал эзләдем.

Моны кем эзләмәгәндер, ләкин табучы булганмы? Адәмнәрнең йөрәген пакьләп, үзара дуст яшәтү, шул юл илә дөньяда рәхәт гомер итеп, саф җан илә Аллага кавыштыру өчен дин килде — килде һәм башта берничә муаффәкыятьле[10] адымнар да ясады, ләкин адәм табигате һаман үзенекен алды: күпме, азмы вакыт үтте, дустлык өчен килгән диннәр адәм балаларын шул дәрәҗәдә аерды, шул дәрәҗәдә дошманлаштырды ки, дин исеменнән түгелгән кан дәрьялары адәм балаларының качан да булса эшли алган явызлыкларының иң куркынычларыннан бере булдылар. Соңра миллият диделәр, аның кодсияте[11] турында тау-тау китаплар язылды. Аңа хезмәт адәм углы өчен иң бөек шәрәф[12] саналды — нәтиҗәдә бүген адәмнең иң тәрбияле, үзен иң гали тоткан сыйныфы шул гали идеал юлында бугазга-бугаз килделәр. Мин вәхши хайваннарның талашын күргәнем бар, ләкин алар үзләренең канга сусауларында бу дәрәҗә вәхшәт күрсәтә алмыйлар.

Фән дидек, гыйлем, мәдәният дидек, боларның бөек куәтенә шөбһә итү — гакылсызлык саналды. Адәм бәхетсез иде, ач, ялангач иде, тирә-якта золым, вәхшәт, гадәләтсезлек күрә иде, ләкин ул фәнгә ышана, мәдәният адәмнәрне тәрбияли, аларга кешелек бирә, аларны дустлыкка, гомуми сәгадәткә алып бара дип өмитләнә һәм шул өмит белән яши иде. Нәтиҗәдә без бу фәннәрнең, бу мәдәниятнең һәммәсе — адәмнең табигатендә булган вәхшәткә, ерткычлыкка корал булудан башка нәрсә түгел икәнен көн кебек күрдек. Әдәбиятмы, сәнгатьме — һәркайда, һәр заманда тук мещаннар белән бай аристократларның эшсезлектән туган эч пошуларын бетерергә хезмәт итә килгән бу ике нәрсәгә һичбер заманда нык иманым булмады, йөрәгем

---

[8]*Яхуд* — яки.
[9]*Фида кылдырырлык* — корбан итәрлек.
[10]*Муаффәкыятьле* — уңышлы.
[11]*Кодсияте* — изгелеге.
[12]*Шәрәф* — дан, хөрмәт.

боларга гашыйк, ләкин гакылым вә вөжданым һичбер вакыт бу икенең җитдиятенә ышана алмый, үземнең гомерем шул икегә хезмәт юлында үтсә дә, рухымның төбендә авыр бер шөбһә ята — башка һәммә нәрсә үзенең кара ягы, ямьсез, мәгънәсез йөзе белән әйләнгән изтираблы[13] минутларда бу ике дә минем кашымда яшәүнең мәгънәсе була алыр дәрәҗәдәге әһәмиятләрен югалтадыр иде. Бу икенең бөтен хәятыңны бирер мәртәбәдә кодси[14] бер хезмәт була алуы, боларда хәятның мәгънәсен күрү — минем өчен бервакытта да шул авыр шөбһә астыннан чыгып җитә алмый иде.

---

Шундый шөбһәләр, газап, изтираблар эчендә йокысыз үткәргән авыр төннәрдән бере иде.

Тар, караңгы бүлмәмнең бер башыннан икенче башына сәгатьләрчә йөреп куәттән тайгач, утырып бераз хәл алдым да бакчага киттем.

Анда дөнья якты, ефәкләр, алтыннар эченә күмелгән ак кул халык бәйрәм итә, музыка күңелле көйләр уйный иде. Кемнәр булгандыр, күрмәдем, күтәрелеп карамадым, ләгънәт дип, каһәр дип, урталарыннан ярып чыктым да, һичкем белән сәламләшмичә, бакчаның артына — кеше йөрми торган башына — зур агачлар арасындагы тын, куе караңгылык эченә таба киттем.

Юлымда берничә чабаталы адәм очрады; алар агачка сөялә төшеп музыка тыңлыйлар, күзләре тәмле нигъмәтләр белән тулган буфетка, андагы симез җилкәләргә кадалган иде. Күз карашларында, шул алтыннар, ефәкләр эченә күмелгән шат йөрүчеләр арасына барырга теләсәләр дә, үзләрен аңа хаклы күрмиләрдер, шуның белән бергә йөрәкләрендә ачу, җәберсенү хис итәләрдер кебек бер төс бар иде.

Туктап сүз кушарга, ни дә булса бер җылы сүз әйтеп, күңелләрен җуатырга теләдем, — нидер тыйды, яннарыннан акрын гына үттем дә, тагы эчкәрәк барып, зур карт имән астындагы аулак бер урындыкка утырачак булдым. Шул вакыт арт ягымнан карлыккан тупас тавыш ишетелде. Карасам — ике сукбай тора.

Агачлар арасыннан сузылып килгән яктыда алар адәмме, җенме дип шикләнердәй бер сурәттә күренделәр. Йөзләре кара, керле, өст-башлары җыртык, аяклары ялангач, күз карашлары ярты дөньяны ашап бетерердәй бер ачлык сөйли иде.

Берсе рустыр, ахры: башында фуражка, йөзендә ят төс; икенчесе, яктыга алды белән торганга, тагы ачыграк күренде. Ул утызның түбән ягында булыр, урта буйлы, чандыр гәүдәле, ач яңаклы бер татар егете иде. Мин

---

[13] *Изтираблы* — борчылулы.
[14] *Кодси* — изге.

килеп утыргач, алар сүздән туктадылар; мине күрүгә, ач яңаклы татарның күзләре киңәеп ачылды да, кемнедер таныырга тырышкан бер дикъкать белән, миңа кадалды. Ул гүя мине таный да, ялгышмыйммы икән дип бераз шөбһәләнә, шул шөбһәне бетерер өчен шул дәрәҗәдә дикъкать итә иде. Шул вакыт ул кинәт бер карарга килде дә, рус иптәшенә нидер әйтеп, кызу-кызу миңа таба атлый башлады.

Аның якынаюы белән мин, ихтыярсыз, урынымнан торып, аякка бастым.

Күзләр адәмнең язмышын сөйләсә, адәмнең эчке дөньясы, хәят юлында кичергәннәре аның йөзендә эз калдыра торган булса, — караңгы бакчада минем каршыма килгән ялангач аяклы, эштән чыккан җыртык киемле бу ач яңак адәм, чынлап та, җәһәннәмнән чыккан булырга тиешле иде.

Аның эштән чыгып бозылган ялангач аягы, өстендәге аркылыдан буйга теленеп, пычранып, җепләр белән бәйләнеп беткән, кайчандыр казакиме, чикмәнме булган хәрабә[15] нәрсәсе — болар гади, бик гади булып калды. Ул гасабича[16] атлап яныма җитүгә, агач арасыннан төшкән якты белән аның йөзе, күз карашы миңа шундый күренде, болардагы бетмәс-төкәнмәс ачлык, болардагы михнәт, җәфа, болардагы бөтен дөньяга, бөтен язмышка каршы ләгънәт, каһәр шул дәрәҗәдә куркыныч бер төс белән ялтырады ки, мин, алдымдагы сурәтнең адәм булуыннан шөбһәләнеп, ихтыярсыз кире чигендем.

Ләкин ул башка мәгънә аңлаган. Ул мине һөҗүмнән курка дип уйлаган ахры, — аяк басуын йомшарта төшеп, яныма ук килде дә, мөмкин кадәр йомшак, ихлас чыгарырга тырышылган бер тавыш белән сүз башлап:

— Курыкмаңыз, мин тимим... Бервакыт мин дә сезнең кебек идем... Сезне укып бик рәхәтләндек, — сезгә рәхмәт, туган, сез бик... — дип минем кулымны кысты.

Читтәрәк торган рус иптәше:

— Абдул, әйдә, соңга калабыз юкса, — диде. Абдул тагы:

— Сезне укып рәхәтләндек, рәхмәт, туган, — дип, ике мәртәбә кулымны кысты да иптәше янына китте.

Мин бу хәлдән айнып, ни булганын аңларлык дәрәҗәгә кайтканда, алар агачлар арасына кереп, караңгылык эчендә югалып баралар иде.

---

Адәм кайбер вакыт юк кына нәрсәгә зур мәгънә бирәдерме, яхуд бу чыннан да шундый мәгънә аңлатырга тиеш идеме? Анысын белмим, ләкин бакчаның караңгы почмагында, ихтимал, бераз исерек тә булган, ул эштән чыккан җыртык киемле бичараның килеп миңа рәхмәт әйтүе, «рәхәтләндек»

[15] *Хәрабә* — тузган, таланган.
[16] *Гасабича* — кызган хәлдә.

дип минем кулымны кысуы авыр шөбһәләрне берьюлы юк итте. Вөҗданыма гаҗиб[17] бер тынычлык бирде. Җанымны тирән шатлык белән тутырды.[*]

Хатыннар — мөлаем һәм дикъкатьле җаннар. Аларның берничә сәламнәре, чәчәкләре мине исертә, кемнәрнеңдер кайчандыр матур сүзләр белән мактавы да миңа зур куәт бирә иде, — ләкин боларның һичбере минем йөрәгемдәге шөбһәне бетерми, тоткан эшемнең бөтен хәятыңны шуңа фида кылыр мәртәбәдә мөһим булган мәгънәсе барлыгын аңлатып җиткерә алмый иде. Үзенең җепләр белән бәйләнеп беткән казакисен өстерәп килгән ул, язмышның мәзлум[18] колы, ач яңак егет миңа рәхмәт укыды, кулымны кысты. [*]Шуның белә йөрәгемә каты таш булып, җанны басып йөргән авыр шөбһә кодрәт кулы илә юк ителде. Шул кечек, гади вакыйгләр[19] минем эшемә зур мәгънә бирде, аяк баскан җиремне ныгытты, күктәге томаннарны, болытларны таратты...

---

[17]*Гаҗиб* — искиткеч.

[*]1914 елгы басмада алда килгән ике җөмлә юк.

[18]*Мәзлум* – рәнҗетелгән.

[*]1914 елгы басмада шушы урыннан алып хикәянең ахыры: *Шуның белән күктәге кара болыт таралды, йөрәктә каты таш булып, җанны басып йөргән авыр шөбһә кодрәт кулы илә юк ителде. Озаккамы, мәңгегәме? – Ансын Тәңре белә...*

[19]*Вакыйгләр*— булган хәлләр.